РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
БУИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ
РАЙОН СОВЕТ
МАЛОБУИНКОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ТАТАР БУАСЫ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

«20» октябрь 2020ел № 4-1

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы
Татар Буасы авыл җирлегендә бюджет процессы
турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә, Буа муниципаль районы Татар Буасы авыл җирлеге Советы

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Татар Буасы авыл җирлегендә бюджет процессы турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2018 елның 14 июлендәге 51-1 номерлы (12.05.2020 № 84-1, 19.08.2020 № 90-1 номерлы карар редакциясендә) карары белән расланган, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Татар Буасы авыл җирлегендә бюджет процессы турындагы нигезләмәгә (алга таба-Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. 6 статья:

2 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

1.2. 31 статья:

1 пунктның 2 абзацын:

«Бюджет акчаларын баш бүлүченең бюджет вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы, җирле үзидарә органы булып торучы казна учреждениесенең бюджет сметасы, әлеге орган җитәкчесе яисә Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә, әлеге орган исеменнән эш итәргә вәкаләтле бүтән зат тарафыннан раслана.»;

1.3. 33 статья:

2 пунктны үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Максатчан билгеләнеше булган (аларны бирү турында хәбәрнамә алган очракта), шул исәптән Россия Федерациясе Бюджет кодексының 242 статьясындагы 5 пунктында билгеләнгән тәртиптә бюджетка керүче субсидияләр, субвенцияләр, башка бюджетара трансфертлар, шулай ук бюджет үтәлеше турында закон (карар) белән расланган керемнәрдән тыш, фактта алынган физик һәм юридик затлардан кире кайтарылмый торган кертемнәр, күрсәтелгән акчаларны бирү максатларына туры килә торган бюджет чыгымнарын арттыруга, агымдагы финанс елына (агымдагы финанс елына һәм план чорына) бюджет турындагы законга (карарга) үзгәрешләр кертмичә, җыелма бюджет язмасына үзгәрешләр кертеп, юллана.»;

1.4. Әлеге карарның 1.1. пункты2021 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

2. Әлеге карар рәсми бастырылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә http://buinsk.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырылырга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп тотуны үземә йөклим.

Буа муниципаль районы Татар Буасы
авыл җирлеге башлыгы, Буа муниципаль районы
Татар Буасы авыл җирлеге Советы рәисе Р.Ф. Юсупов